РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Уразлинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Мира, 7,с. Уразлино, 422838
тел. (8277)33-2-31, факс: (8277) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Уразлы**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Тынычлык урамы, 7,Уразлы авылы, 422838,
тел. (8277)33-2-31, факс: (8277) 33-2-31
ОКПО 94304522, ОГРН 1061672020497
ИНН/КПП 1622004732/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
«10» октября 2018г № 14

2017 елның 20 июнендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентын раслау турында”гы 5 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛА:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 июнендәге 5 номерлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8, 9 пунктчалары белән тулыландырырга:

“8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән күздә тотылмаган очракта, бирү яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору.”;

1.2. 5 бүлекнең 5.12 пунктының 1-3 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә шикаять канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Уразлино авылы, Тынычлык урамы, 7 йорт (СП администрация бинасы);

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Карамал авылы, Кече урамы, 1 нче йорт (Кече Карамал авыл мәдәният йорты),

шулай ук Хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Уразлы авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе: М. Г. Хәмидуллин**